Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының "Салман авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советы карары белән кабул ителде 2025 елның «08» августы № 108

# Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына Үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Салман ав.

РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
СОВЕТ
Салманского сельского
поселения Алькеевского
муниципального района

ТАТАРСТАНРЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки муниципаль районы
Салман авыл җирлеге
СОВЕТЫ

Адрес:422874, Республика
Татарстан, Алькеевский район,
с.Салманы,
ул. Молодёжная, д.12.
тел: 8 (84346) 72-2-38

Адресы:422874,Татарстан
Республикасы, Әлки районы,
Салман авылы,
Яшьләр ур., 12.
тел.: 8 (84346) 72-2-38

**РЕШЕНИЕ** **Салман ав.** **КАРАР**

2025 елның " 08 " августы № 108

Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге Советының 23.10.2023 елның 64-нче номерылы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы "Салман авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставын раслау турында " карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (соңгы үзгәрешләре белән), «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Әлки районы Прокуратурасының хокук булдыру инициативасын өйрәнеп, муниципаль берәмлек Уставының 85,86 статьялары нигезендә «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Салман авыл җирлеге Советы **карар кабул итте**:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 23.10.2023 елның 64-нче карары белән (29.07.2024 елның 85-нче карары редакциясендә) 1 нче кушымта нигезендә расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

3. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы статьяларының яңа

редакциясен дәүләт теркәвенә алганнан соң Салман авыл җирлеге территориясендә махсус җиһазландырылган стендларда: Татарстан Республикасы, Әлки районы, Салман авылы, Яшьләр урамы , 12 йортта (җирле үзидарә бинасы) халыкка җиткерергә; Татарстан Республикасы, Әлки районы, Салман авылы, Мәктәп урамы, 19 йорт (авыл мәдәният йорты) һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында (http://alkeevskiy.tatarstan.ru.) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
«Салман авыл җирлеге»
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Советы Рәисе

И. В. Йосыпов

1 нче кушымта
Әлки муниципаль районы
Салман авыл җирлеге
Советы карарына
08.08.2025 ел, № 108

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының "Салман авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1. 5 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 19.1 пункт өстәргә:
"19.1" шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112 номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып барган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру".